РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«25» апрель 2024 ел г. Альметьевск № 1601

Гражданнарны наем шартнамәләре
буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар
дип тану максатларында гражданнарның
һәм алар белән бергә даими яшәүче гаилә
әгъзаларының керемнәре һәм аларның
салым салынырга тиешле мөлкәтләре
хакының максималь күләмен билгеләү турында

«Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елга гражданнарны наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип тану максатларында гражданнарның һәм алар белән бергә даими яшәүче гаилә әгъзаларының керемнәре һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәтләре хакының максималь күләмен түбәндәге очракларда билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләме:

1.1.1. Ялгыз яшәүче гражданин өчен - 1 426 518 сум;
1.1.2. Ике кешедән торган гаилә өчен – 2 853 036 сум;
1.1.3. Өч кешедән торган гаилә өчен – 4 279 554 сум;
1.1.4. Дүрт кешедән торган гаилә өчен – 5 706 072 сум;
1.1.5. Биш кешедән торган гаилә өчен – 7 132 590 сум;
1.1.6. Алты кешедән торган гаилә өчен – 8 559 108 сум;
1.1.7. Җиде кешедән торган гаилә өчен – 9 985 626 сум;
1.1.8. Сигез кешедән торган гаилә өчен – 11 412 144 сум.

1.2. Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме тәшкил итә:

1.2.1. Ялгыз яшәүче гражданга – 53 947 сум;
1.2.2. Ике кешедән торган гаилә өчен – 53 947 сум;
1.2.3. Өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаилә өчен - 53 947 сум.

2. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Гражданнарны наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип тану максатларында гражданнарның һәм алар белән бергә даими яшәүче гаилә әгъзаларының керемнәре һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәтләре

заказ № 1-851

хакының максималь күләмен билгеләү турында» 2021 елның 9 мартындагы 307 номерлы карарын үз көчен югалткан дип таныргa.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары вазифаларын башкаручы А. А. Ямалетдиновка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов